КОЛЛЕКТИВ И ПРОФКОМ ТЕПЛО ПОЗДРАВИЛИ, ЧЕСТВОВАЛИ ЮБИЛЯРОВ И ВРУЧИЛИ ПОДАРКИ




Не каждый год такая дата!
Не каждый год, ведь, юбилей!
И поздравленья – очень важны,
В такой прекрасный, добрый день!
Для многих – Вы богиня неба!
Для многих – водопад страстей!
Мужчины о таких мечтают,
С такими жизнь, ведь, веселей!
Пусть Вам удача улыбнется,
А жизнь, пусть, сказкой обернется!

Страница ППО на сайте E-Mail: goroddou12@mail.ru

Телефон: 8(85595) 5-19-80



**Хөрмәтле Зәйтүнә Минвалиевна!**
Чын күңелдән бәйрәмегез белән
Сезне коллектив тәбрик итә.
Бик күп матур сүзләр, кайнар котлау,
Изге теләкләр бүләк итә.
Юбилярга озын гомер телик,
Бәхет,шатлыкюлдашбулсыннар.
Якын кешеләре һәрвакытта,
Гомер буе тугры булсыннар.
Күк йөзләре һәрчак аяз булсын,
Өстәлләре ризык белән тулсын,
Туганнары сау- сәламәт булсын,
Йөзләрендә бәхет балкып торсын.
Хасанова Рәсилә шигыре.



**ХөрмәтлеТәслимә Асхатовна.**
Бүген сезнең шатлыклы көнегез.
Бүген сезнең гомер бәйрәмегез.
Бүләк булсын сезтәбрикләүләр,
Назлы, матур чәчкә бәйләмебез.
Утыз елдан артык шул бакчада
Намус белән хезмәт итәсез.
Һәр киләчәк көнне, туар таңны
Гел куаныч белән көтәсез.
Колективта 59 кеше,
190 га якын бала бар.
Кабинеттан кеше бер өзелми,
Төрлесендә исә төрле зар.
Һәрберсенә ярдәм күрсәтәсез,
Моң- зарларын тыңлый беләсез.
Хезмәтегез бик тә җаваплы.
Хезмәтегез бик тә саваплы.
Без телибез сезгә озын гомер,
Нык исәнлек, бик күп шатлыклар.
Күк йөзләре һәрчак аяз торсын,
Ак бәхетләр юлдаш булсыннар.
Хасанова Рәсилә шигыре.



**Хөрмәтле Нурия Гатуфовна!**
Бер карауга гади генә кеше,
Якты йөзле, үзе сөйкемле.
Янәбызда ул булган чакларда
Безгә рәхәт, безгә күңелле.
Ул сәхнәгә чыкса бар да көлә,
Киеменнән, әллә йөзеннән.
Карашыннан,басып торышыннан,
Бәлки аның шаян сүзеннән.
Бәйрәмнәрдә бакчабыз сәхнәсен
Әкияттәге төсле бизи ул.
Алдан матур итеп рәсем ясый.
Үзе шундук план төзи ул.
Сул кулына ала да каләмен
Уңга, сулга нидер сызгалый.
Рәсеменә янә күз төшергәч,
Төрле буяу белән баскалый.
Рәсем әзер, күз явын алырдай.
Рәссамнар да шулай язалмас.
Һич шигем юк, аның иҗатына
Беркем дә битараф калалмас.
Кулына ала да бер кәгазьне
Аннан тарта, моннан бөгәрли.
Чәчкә, аккош, песи, тычкан һәм эт
Килеп чыга, я ат йөгәрле.
Менә шундый тылсымнарга ия,
Кулларыннан гөлләр сибелә.
Аның каршында баш иелә,
“Иҗат кешесе ул”- диелә.
Хасанова Рәсилә шигыре.




**ХөрмәтлеЛилия Саффановна!**
Чын күңелдән бәйрәмегез белән
Сезне коллектив тәбрик итә.
Бик күп матур сүзләр, кайнар котлау,
Изге теләкләр бүләк итә.
Сезнең хезмәт барсына да үрнәк,
Сез чисталык, сафлык иясе.
Сезнең теккән күлмәк, итекләрне
Һәркемнең дә килә киясе.
Йөзегездә һәрчак кояш балкый,
Тирә- якка җылы наз сибә.
Сезнең күркәм йөзегезне күргәч,
Бары тик елмаясы килә.
Хасанова Рәсилә шигыре.



**ХөрмәтлеЛилия Рифхатовна!**

Чынкүңелдәнбәйрәмегез белән
Сезне коллектив тәбрик итә.
Бик күп матур сүзләр, кайнар котлау,
Изге теләкләр бүләк итә.
Чын йөрәктән әйтәм сезнең хезмәт
Күп буынга үрнәк булырлык.
Балаларга әйткән һәр сүзегез
Алтын бәясендә торырлык.
“Сүзе- китап, үзе- китапханә”,
Диләр сездәй зирәк кешегә.
Теләгән сорауга тулы җавап,
Киңәш бирәсез сез һәркемгә.
Чиксез белем, тәрбия бирәсез,
Хезмәтегез бик тә хөрмәтле.
Күпме бала- чага, ата-ана
Чын күңелдән сезгә рәхмәтле.
Насыйп булсын иде озак вакыт
Сезнең белән хезмәт итәргә.
Дөрес тәрбия һәм белем
Яшь буынга бүләк итәргә.
Хасанова Рәсилә шигыре.



**ХөрмәтлеТәнзилә Ракиповна!**
Чын күңелдән бәйрәмегез белән
Сезне коллектив тәбрик итә.
Бик күп матур сүзләр, кайнар котлау,
Изге теләкләр бүләк итә.
Сезнең хезмәт ихтирамга ия,
Сезнең куллар алтын ләбаса.
Шул арада тәмле аш пешерә,
Токмач кисә, камыр да баса.
Бик күп еллар тәмле ризык белән
Балаларны, безне сыйлыйсыз.
Менюыгыз гел үзгәреп тора,
Төрле- төрле сыйлар сайлыйсыз.
Тикшерүләр килгәч өстәлләрдә
Торса сез пешергән өчпочмак,
Эшләр пешә, бар да риза кала,
Кәеф яхшы, чөнки тамак тук.
Хасанова Рәсилә шигыре.



**ХөрмәтлеРузиләГарафовна!**
Чынкүңелдәнбәйрәмегез белән
Сезне коллектив тәбрик итә.
Бик күп матур сүзләр, кайнар котлау,
Изге теләкләр бүләк итә.
Сез ягымлы,шат күңелле кеше,
Сезнең йөздә бәхет ялкыны.
Сез булганда кайгылар тарала,
Сизелмидер кышның да салкыны.
Сезнең янда һәрчак бала- чага,
Яраталар сезне, назлыйлар.
Каз бәбкәләредәй тезелешеп
Артыгыздан бер дә калмыйлар.
Олы җанлы кеше булу кирәк
Сабыйларның серен аңларга.
Күпме кирәк вакыт һәм сабырлык
Аларның моң- зарын тыңларга.
Олыга да, кечегә дә үрнәк
Тормышыгызның һәр мизгеле.
Сүзләрегез, биргән киңәшегез
Безнең өчен бик тә кирәкле.
Хасанова Рәсилә шигыре.

**Первичная профсоюзная организация работников МБДОУ №12**

**Иформационный бюллетень №3**

## Поздравление юбиляров.

Уважаемые сотрудники!

В 2013 году в нашем детском саду свой юбилей отметили 7 сотрудников.

Мы от души поздравляем их.